ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

от 30.11.2016 г. Казань № 10-24/кс

2017 елга эчергә яраклы суга, су бүлүгә һәм ташландык суларны чистартуга тарифлар билгеләү турында

"Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында" 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, "Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында" 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, "Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны исәплəп чыгару буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында" тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 27 декабрендәге № 1746-э санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы оешмаларга эчергә яраклы суга, су бүлүгә һәм ташландык суларны чистартуга тарифларны билгеле бер календарь чорларына бүлеп, әлеге карарның кушымтасы нигезендә билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2017 елның 1 гыйнварыннан 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Әлеге карар кушымтасында күрсәтелгән салкын су белән тәэмин итүче һәм су бүлүне башкаручы оешмаларга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 санлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты 2016 елның
30 ноябрендәге 10-24/кс санлы
карарына кушымта

2017 елга салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы оешмалар өчен
клендарь чорларына бүлепэчергә яраклы суга, су бүлүгә һәм ташландык суларны чистартуга тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы оешма | эчергә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | су бүлүгә тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | ташландык суларны чистартуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр |
| | Балтач муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | “Торак-коммуналь хуҗалыгы Ципьинск күп тармаклы җитештерү предприятиесы” җаваплыгы чикләнгән җәмгыять * | 25,87 | 26,63 | | | | |
| | Чүпрәле муниципаль районы | | | | | | |
| 2 | “Чүпрәле коммуналь челтәрләре”* җаваплыгы чикләнгән җәмгыять | 32,42 | 33,02 | 31,64 | 32,60 | | |
| | Лениногорск муниципаль районы | | | | | | |
| 3 | “Вода района”* җаваплыгы чикләнгән җәмгыять | 30,10 | 30,10 | | | | |
| | Мамадыш муниципаль районы | | | | | | |
| 4 | “ПРОСТО МОЛОКО” идарәче компания” җаваплыгы чикләнгән җәмгыять | | | | | | |
| 4.1 | “Мамадыш сыр-май комбинаты” “ПРОСТО МОЛОКО” Идарәче компания җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять филиалы (тарифлар НДСны исәпкә алмыйча күрсәтелгән) | | | | | 10,34 | 11,06 |
| | Черемшән муниципаль районы | | | | | | |
| 5 | “Черемшән районы коммуналь челтәрләре”* | 25,99 | 26,99 | 42,35 | 43,65 | | |

| № п/п | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы оешма | эчергә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | су бүлүгә тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | ташландык суларны чистартуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр |
| | муниципаль унитар предприятиесы | | | | | | |

---

<*> салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
Дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге